**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күлле-Киме авыл җирлеге Яңа Бәрәскә торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“5” ноябрь 2021 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №109 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Яңа Бәрәскә торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Яңа Бәрәскә авылы территориясендә 2022 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Яңа Бәрәскә авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 5000 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Яңа Бәрәскә авылына юл ремонты, вак таш сатып алу һәм транспорт өчен түләү,
- Яңа Бәрәскә авылы территориясен чистарту һәм чүп-чар җыештыру.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Яңа Бәрәскә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күлле-Киме авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Яңа Бәрәскә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы Гәрәев Х.Х.